ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.08.2020 Олы Кайбыч ав. № 400

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тулы канлы тукландыруны тәэмин итү, СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәү, шулай ук гомуми белем бирү оешмалары укучыларының аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануы өчен ата-ана взносларын түләүдән түбәндәге категория укучыларны азат итәргә:

- ятим балалар һәм опекада торучы балалар;
- инвалид балалар;
- җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз тәэмин ителгән гаиләләрдән балалар;
- дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдәге балалар;
- балаларны яки баланы ата-аналарның берсе тәрбияләгән тулы булмаган гаиләләрдән балалар.

2. Укучыларны тукландыру максатларында муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

2.1. Мәктәп бакчаларында җыелган уңышны тиешле санитария-гигиена нормаларына туры килә торган итеп кулланырга.

2.2. Төп туклыклы матдәләрнең эчтәлеге буенча балансланган кайнар туклануны укучылар өчен оештырырга.

2.3. Мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.

2.4. Башлангыч белем бирү программалары буенча 51 (илле бер) сум 85 тиен күләмендә түләүсез кайнар аш белән тәэмин итәргә.

2.5 Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны 7 сум 70 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-ана түләвеннән (законлы вәкилдән) торган суммага тукландыруны оештырырга.

3. Бер кешегә туклану бәясе тәкъдим ителгән санитария кагыйдәләре тарафыннан азык-төлек җыелмасы составына кертелгән туклану продуктларына булган бәяләрдән чыгып төзелә дип билгеләргә.

Туклану бәясен арзанайту гомуми белем бирү оешмаларының ярдәмче участокларында үстерелгән продуктлар исәбенә гамәлгә ашырыла.

4. Гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның туклануы өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләү күләме гомуми белем бирү оешмасы директоры тарафыннан расланган һәм Кулланучылар хокукларын яклау һәм Татарстан Республикасы буенча кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте идарәсе белән килештерелгән меню нигезендә туклануга чыгымнарны каплау күләмен исәпкә алып дифференциацияләнгән дип билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгына:

5.1. Укучыларның кайнар туклануын оештыруга бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә.

5.2. Витаминнар һәм микроэлементлар белән баетылган төп туклыклы матдәләрнең эчтәлеге буенча балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын тикшереп торуны тәэмин итәргә.

5.3. Мәктәп алды участоклары продукциясе исәбенә мәктәп ашханәләре ассортиментын баету эшен оештырырга.

5.4. Гомуми белем бирү оешмаларына продуктларның өзлексез керүен координацияләүне һәм тикшереп торуны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына укучыларның туклануына җирле бюджеттан ассигнованиеләр исәбеннән гомуми белем бирү оешмалары эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә каралган акчаларны үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

7. «2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2020 елның 14 гыйнварындагы 15 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат» рәсми порталында бастырып чыгарырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров